КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 июль г.Казань № 546

Татарстан Республикасының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, мәктәпкәчә белем бирү буенча бюджет белем бирү хезмәтләренең сыйфатын яхшырту максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе (алга таба – Тәртип);

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караштырып тору һәм карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрне;

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мөлкәтне карап тоту өчен норматив чыгымнарны, коммуналь хезмәтләргә түләү чыгымнарын, элемтә хезмәтләре күрсәтү өчен норматив чыгымнарны, бассейннарны карап тоту өчен норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрне;

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында балаларны караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу буенча методик тәкъдимнамәләрне;

Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү күләмен исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрне.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икъ-тисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен норматив чыгымнарын бу карарның 1 нче

пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгаруны гамәлгә ашырырга.

3. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне бу карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән методик тәкъдимнамәләр нигезендә эшләүне һәм раслауны тәкъдим итәргә:

муниципаль районның (шәһәр округының) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караштырып тору һәм карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибен;

муниципаль районның (шәһәр округының) мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын финанслар белән тәэмин итү күләмен исәпләп чыгару тәртибен;

муниципаль районның (шәһәр округының) мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында балаларны караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибен.

4. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 25 июль, 546 нчы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 8 февраль, 76 нчы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 31 март, 201 нче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 13 ноябрь, 996 нчы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 1 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караштырып тору һәм карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләргә үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 29 декабрь, 1267 нче карары;

5. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин